**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об объявлении траура в связи с трагическими событиями в Республике Татарстан

Выражая скорбь по погибшим в результате трагических событий, произошедших в муниципальном бюджетном общеобразовательном учреждении «Гимназия № 175» Советского района г. Казани 11 мая 2021 года, соболезнуя их родным и близким, **постановляю:**

1. Объявить 12 мая 2021 года днем траура в Республике Татарстан.

2. В день траура на всей территории Республики Татарстан приспустить Государственные флаги Республики Татарстан.

3. Предложить телерадиокомпаниям и учреждениям культуры отменить развлекательные передачи и мероприятия в день траура.

4. Кабинету Министров Республики Татарстан подготовить предложения по оказанию помощи семьям погибших и пострадавшим в результате трагических событий.

5. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
11 мая 2021 года
№ УП-350

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында фаҗигале вакыйгалар белән бәйле рәвештә матәм игълан итү турында**

2021 елның 11 маенда Казан шәһәре Совет районының «175 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә булган фаҗигале вакыйгалар нәтиҗәсендә һәлак булганнар турында авыр кайгы белдереп, аларның туганнары һәм якыннарының хәсрәтен уртаклашып, **карар бирәм:**

1. 2021 елның 12 маен Татарстан Республикасында матәм көне дип игълан итәргә.

2. Матәм көнендә Татарстан Республикасының бөтен территориясендә Татарстан Республикасы Дәүләт флагларын түбәнрәк төшерергә.

3. Телерадиокомпанияләргә һәм мәдәният учреждениеләренә матәм көнендә күңел ачу тапшыруларын һәм чараларын үткәрмәскә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына фаҗигале вакыйгалар нәтиҗәсендә һәлак булганнарның гаиләләренә һәм зыян күрүчеләргә ярдәм итү буенча тәкъдимнәр кертергә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 11 май
№ ПУ-350